ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.01.2026 Балык Бистәсе штп. №11пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының баш бухгалтерларына һәм бухгалтерларына һәм үзәкләштерелгән бухгалтерияләрнең җитәкчеләренә һәм белгечләренә (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 27.05.2019 ел, №181пи карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Шәһәр һәм авыл җирлекләре бухгалтерларының һәм үзәкләштерелгән бухгалтерияләрнең җитәкчеләренә һәм белгечләренә 2026 елның 1 гыйнварыннан билгеләнә торган хезмәт өчен түләү турында» 27.10.2025 ел, №03-12/7278 хаты нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының баш бухгалтерларына һәм бухгалтерларына һәм үзәкләштерелгән бухгалтерияләрнең җитәкчеләренә һәм белгечләренә (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 27.05.2019 ел, №181пи карарына түбәндәге үзгәрешләргә үзгәрешләр кертергә:

1.1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-хуҗалык бүлекләре җитәкчеләренә һәм белгечләренә хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турындагы нигезләмәнең 3 пунктын " түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-хуҗалык бүлекләре җитәкчеләренең һәм

белгечләренең вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләр вазыйфалары | Вазифаи оклад, сумнарда | |
|---|---|---|
| | Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен | Башкарма комитетның (җирле үзидарәнең башка органының) структур бүлекчәсе (бүлеге) булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 40 700 | |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 38 100 | |
| Башкарма комитетның структур бүлекчәсе җитәкчесе (баш бухгалтер) | | 38 100 |
| Бүлек начальнигы | 33 600 | 33 600 |
| Әйдәүче бухгалтер | 30 600 | 30 600 |
| Бухгалтер | 29 000 | 29 000 |

Муниципаль учреждение булып торган үзәкләштерелгән бухгалтериянең штат расписаниесенә җитәкче урынбасары вазыйфасын кертү шарты булып структурада һәркайсында 5 берәмлектән дә ким булмаган кимендә 3 бүлек булуы тора.

Үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлекләренең штат саны кимендә 5 берәмлек булырга тиеш.»;

1.1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының баш бухгалтерларына һәм бухгалтерларына (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлар турындагы нигезләмәнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бухгалтерларның вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазифа | Халык саны буенча муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары | |
|---|---|---|
| | 3,5 мең кешегә кадәр | 3,5 мең кешедән артык |
| Баш бухгалтер | 31 000 | 32 700 |
| Бухгалтер | - | 29 700 |

2. Хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычлары күләме һәм шул ук квалификациядәге эшләр башкарылуы сакланып калганда, хезмәткәрләрнең

хезмәт хакының әлеге карар нигезендә билгеләнә торган күләме 2025 елның 31 декабренә түләнә торган хезмәт хакы күләменнән ким була алмый.

3. Әлеге карар үз көчен 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерә

4. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе И. М. Ногмановага йөкләргә.

Җитәкче Д.А. Сатдинов